ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“15” октябрь 2020 ел Казиле авылы №12

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Казиле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Кнәз авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Княз авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2020 елның 05 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Казиле авылында, Подгорная ур., 27а йортында узачак.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез Кнәз авыл җирлеге территориясендә 2021 елда бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләү кертергә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз карт гражданнар һәм күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүләрне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз) сум күләмендә билгеләргә килешәсезме?:
- Казиле т. п. юлын ремонтлау;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга Стелла тирәли брусчатка җәю.

“ӘЙЕ” “ЮК".

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы , Казиле авылы, Подгорная урамы, 27а (клуб).
4. Халык җыенын Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлеге башкарма комитеты оештырды.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Камалов

ОГРН 1061682004515
Исполнительный комитет
КНЯЗЕВСКОГО
сельского поселения
ИНН 1639032255